# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча
гадәттән тыш чаралар турында

Әлеге закон җинаятьчелеккә каршы көрәшне көчәйтүгә, шәхеснең, җәмгыятьнең һәм дәүләтнең иминлеген тәэмин итүгә юнәлтелгән.

1 ~~нче~~ статья. 1994 елның I гыйнварена кадәр Татарстан Республикасы Президентына түбәндәгеләр өчен өстәмә вәкаләтләр бирергә:

Татарстан Республикасының тиешле законнарын кабул иткәнчегә кадәр, җинаятьчелеккә каршы юнәлдерелгән һәм законнарга тиңләштерерлек әмерләр чыгарырга;

республика хокук саклау органнарының җитәкчеләрен һәм Татарстан Республикасы Премьер-министрының хокук саклау эшчәнлеген җайга салу буенча урынбасарын вазифаларыннан азат итәргә һәм билгеләргә.

2 ~~нче~~ статья. Җинаять эшләрен булдырмау һәм кисәтү максатларында, Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт иминлеге комитетына түбәндәге хокукны бирергә:

милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмаларның биналарын карау, кемнеке булуына карамастан, барлык төр транспортларны, шулай ук аларның шоферларын һәм пассажирларын тикшерү;

зур җинаятьтә катнашу шиге уяткан төркемнәрнең актив әгъзаларын һәм аерым кешеләрне 30 тәүлеккә кадәр сак астында тоту.

3 ~~нче~~ статья. Татарстан Республикасының "Дәүләт хезмәте турында"-

гы Законын кабул иткәнчегә кадәр, дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары хезмәткәрләренә, җитәкчеләргә һәм аларның урынбасарларына, шулай ук барлык төр дәүләт предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре бүлекчәләре җитәкчеләренә эшкуарлык эшчәнлегендә катнашуны тыярга.

4 статья. Бу Закон һәм аның нигезендә басылган актлар 1994 елның 1 гыйнварена кадәр гамәлдә булачак.

5 статья. Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе хокук актларының бу Законга каршы килүче нигезләмәләрен Татарстан Республикасы территориясендә 1994 елның 1 гыйнварена кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
25 май, 1993 ел